**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

05.06.2018 553-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 02.10.2013 № 561-п, 17.10.2016 № 1103-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.4 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.»;

1 бүлекнең 1.9 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексы 2000 елның 05 августындагы № 117-ФЗ (РФ Салым кодексы № 117-ФЗ);»;

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында 9 пункт өстәргә «9. Лицензия дубликаты бирү»;

2.5 пунктта «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 35.2., 35.3., 35.4., 35.5., 35.8., 35.8.1 ст.; 715 номерлы ТР МК карарының 2.1, 4.2, 4.3, 4.4 п.п.;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында «кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән» сүзләрен «почта юлламасы белән» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.10 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Лицензияләр реестрыннан белешмәләр түләүсез бирелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, Министрлык һәм (яисә) вазыйфаи зат, күпфункцияле үзәк һәм (яисә) күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен юлланган документка үзгәрешләр кертелгән очракта мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.»;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм документлар килгән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә»;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.15 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«5) инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.»

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.1. Бүлек хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Реламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләре саклануын һәм үтәлүен агымдагы тикшереп тору бүлек башлыгы тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре саклануына һәм үтәлүенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бүлек башлыгының карарлар кабул итүенә агымдагы контрольне оештыру тәртибен һәм формаларын министр урынбасары билгели.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык бүлегенең әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган, вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә торган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

белешмәләрне һәм документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

гаризаларны һәм документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә нәтиҗәләрне тапшыру вакытлары һәм тәртибе үтәлүенә.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерергә хокуклы, судка кадәр тәртиптә, – Министрлыкка. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның дәүләт хезмәткәренең, җитәкчесенең гамәл кылу карарына (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://gosuslugi.ru), күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне

эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.».

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министр урынбасары Р.Н.Гайнетдиновны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков